ГАЗЕТА МБОУ «Арская СОШ№2» г. АРСК РТ

Апрель 2017 год

# Пульс школы



**Школа — это мастерская, где формируется мысль подрастающего поколения, надо крепко держать ее в руках, если не хочешь выпустить из рук будущее.**

**Анри Барбюс**

### *26 нчы апрель – Габдулла Тукай туган көн!*



Тукай - шигъри кыябыз
Ул күз ачкан синдә, Кушлавыч,
Мирас булган ятим бусага.
Читләп узган наз һәм куаныч,
Түзгән сабый, ачлык булса да.
Үпкә чире тынын кысса да
Исән калган шигъри каһарман.
Шигъри кояш ул - күк кысада,
Жылы иңә жанга аңардан.
Шагыйрьләрнең тирән эзлесен
Очратсак та кайчак арада,
Үзенең дан, иман көзгесен
Татар халкы күрә аңарда.
Ул - син, Тукай.
Ә син - мәңгелек:
Гел яшисең жиргә ямь биреп!

Апрель - безгә бөек Тукаебызны биргән ай. Ничә еллар инде без Тукайга тере чәчәкләр китерәбез, шагыйрьгә, аның шигъриятенә мәдхия жырлыйбыз. Олуг шагыйребезгә елдан-ел көчәя барган мәхәббәтебезне, хөрмәтебезне белдерәбез.

Татар дөнясында Тукай исеме - мәдәни тормышыбызның үзәге, сәяси кыйблабызның маягы. Аның әсәрләре заман сулышын тоюда, әдәбиятта бара торган юнәлешләрне аңлауда иң зур бизмән булып тора. Тукай - һәрчак халыкныкы, аның бәгъреннән өзелеп төшкән үз улы. Тукай - халкыбызның теле дә, моңы да, рухы да, язмышы да.

### *Тел - халык күңеленең кыңгыравы*

26 нчы апрель - бөек шагыйребез Габдулла Тукайның туган көне. Татар милләте өчен бу көн - бәйрәм көн. Шуңа күрә укучыларыбыз милли киемнәрдән килделәр. Бүген дөнья халыклары 6 мең телдә сөйләшә. Һәркем өчен дөньядагы иң кадерлесе - беренче сөйләшә башлаган ана теле. Барлык телләрдә тигез дип таныла, чөнки аларның һәркайсы кеше язмышы өчен җавап бирә һәм без аны сакларга тиешбез. Татар теле дәрәҗәле 14 телнең берсе.

Татар телен белгән кеше 30 артык төрле халык белән аралаша ала. Үзебезнең арада да татар теле нигә кирәк ул, аның белән кая барып була диючеләр бар. Аларга милләттәшебез Садри Максуди җавап бирә кебек: ” Телебезне өйрәнми башлаган көннән башлап бетә башлаячакбыз.

Безнең бер милләт булып тора алуыбыз, телебезне саклый алуга бәйледер. Телебезне саклый алсак, бер милләт булып тора алырбыз, әгәр телебезне саклый алмасак, милләтебездән мәхрүм булырбыз! Газиз туган телебезне кадерлик, яклыйк, саклыйк. Туган теле барның милли юлы бар, милли йөзе бар.

### *Шигырь бәйгесе*

Бүген районкүләмендә уздырылган күренекле татар халык шагыйре Г.Тукайга багышланган "Тукай безнең йөрәкләрдә" исемле бәйгедә 8 нче А сыйныфы укучысы Никитина Зәринә у ңышлы чыгыш ясап, II дәрәҗә Диплом (укытучысы Г.Р.Мөбәрәкшина), 5 нче А сыйныфы укучысы Асадуллин Нияз Сертификат белән бүләкләнде (укытучысы Г.А.Гарипова).Аларны ихластан котлыйбыз!

### *Шигырь бәйгесе*

25 нче апрельдә районкүләмендә уздырылган күренекле татар халык шагыйре Г.Тукайга багышланган "Тукай безнең йөрәкләрдә" исемле

## *Бөеклеге аның - халыктан*

26 нчы апрель көнне Арча үзәк китапханәсендә "Тукай белән көчле без " дигән әдәби - музыкаль кичә үткәрелде. Бу кичәдә мәктәбебезнең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Л.Ә. Фатыхова Тукайның этисе ягыннан булган туганлык җепләрен сүтте, ә 8в сыйныфы укучысы ,шагыйрьнең әнисе ягыннан бишенче буын туганы Зөләйха Зәбирова үзе иҗат иткән шигырен сөйләде. Әдәби кичәдә Тукай иҗатын яратып өйрәнүчеләр һәм Тукайга багышлап шигырь иҗат итүчеләр дә чыгыш ясады. Кичә "Туган тел " җырын башкарып тәмамланды.

## *Безнең күңелләрдә син, Тукай!*

28 нче апрельдә үткәрелгән "Безнең күңелләрдә син, Тукай!" кичәсенә тырышып әзерләндек. Әкият геройларының киемнәрен үзебез кулдан тектек. Әбиләрнең күлмәкләре, бабайларның түбәтәйләре дә ярдәмгә килде. "Кәҗә белән Сарык" әкиятен сәхнәләштердек. Шагыйребезнең тормыш юлын тагын бер кат искә төшердек. Нәни Апуш, этисе Мөхәммәтгариф белән очрашкандай булдык. Кичәбез күңелле җырлар, дәртле биюләр белән үрелеп барды. Бик күңелле булды.

Габдулла Тукайның иҗатын киләчәк тә дә өйрәнүне дәвам итәрбез. Аның иҗаты белән горурланабыз. Әкиятләрен яратып укыйбыз.

*Гөлназ Миңлебаева*, 5 В сыйныфы



## *Кешене белем бизи*

14 апрель көнне Яңа Кырлай мәктәбендә Габдулла Тукайның иҗади мирасын өйрәнүгә багышланган VI Республикакүләм Габдулла Тукай укулары булды.

Бу укулар быел алтынчы тапкыр үткәрелә. Катнашучылар саны да елдан ел арта. Быел 75 укучы һәм 44 укытучы килгән.

Барлыгы 325 эш кабул ителгән. Шуларның 136сы уңышлы дип табылган. Төрле районнардан килгән катнашучылар сигез номинациядә чыгыш ясады, әдәби мирасыбызны тирәнтен өйрәнүләрен, белүләрен раслады.

Жюри әгъзалары да дәрәҗәле шәхесләр иде. "Казан утлары" журналыннан проза бүлеге мөхәррире Камил Кәримов, җаваплы сәркатибе Вакыйф Нуриев, баш мөхәррир урынбасары Рамил Ханнанов, Казан федераль университеты филология һәм сәнгать институты доценты, филология фәннәре кандидаты Флера Сәйфуллина, "Безнең мирас" журналының тарих, дин һәм педагогика бүлеге мөхәррире Ленар Гөбәйдуллин һәм башкалар эшләргә бәя бирде.

Соңыннан Тукай укуларында катнашкан һәр укучы, укытучыга сертификатлар, истәлек бүләкләре тапшырылды, җиңүчеләр бүләкләнде.

Алар арасында безнең мәктәбебездән 9 нчы сыйныф укучылары: Халиуллина Миләүшә (җитәкче Ибраева Р.Х.), Хадыкина Екатерина (җитәкче Мөбәрәкшина Г.Р.) сертификат,7 нче сыйныфтан Шәрипов Рүзәл (җитәкче Ибраева Р.Х.) II дәрәҗә дипломга лаек булдылар. Татар теле һәм әдәбияты укытучылары арасында Л.Ә.Фатыхова III дәрәҗә дипломга, Р.Х.Ибраева сертификатка ия булдылар.

## *Тукай марафоны*

Бөек шагыйребез Габдулла Тукайның тууына 131 ел тулу уңаеннан, елдагыча, традиция буенча, 27 нче апрельдә Арчада җиңел атлетика буенча «Тукай марафоны - 2017» дип исемләнгән 10 чакрым дистанциядә чабу оештырылды. Безнең мәктәптән 7 нче б сыйныфы укучысы Дияров Илназ III урынны яулады. Марафончыларны 8 сыйныф укучылары катнашында оештырылган флэшмоб биючеләр каршы алды.

Әлеге чара районыбызда берничә ел үткәрелә. Марафонда катнашучы республикабыз кунаклары шагыйребезнең туган авылы Кушлавычта, бәләкәй Апушны сыендырган Кырлай авылында булалар. Бу көнне Тукай премиясе лауреатлары, бер төркем язучылар шагыйрьнең һәйкәленә чәчәкләр куялар.

## *Региональная научно-практическая конференция*

20 апреля на базе нашей школы прошел II этап региональной научно-практической конференции «Экологическая безопасность современных социально-экономических систем в ракурсе Хартии Земли». Она была приурочена к знаменательной дате – Дню Земли и Году Экологии в России.

Участниками данной конференции стали больше 50 обучающихся образовательных учреждений, которые занимаются исследовательской и творческой деятельностью в различных областях науки.

Работа велась в двух направлениях. I Секция - «Окружающая среда и здоровье человека», II Секция - «Проблемы экологии в произведениях русских и татарских писателей».

Участники должны были подготовить публич-

## *Үз юлым*

2 нче апрель көнне “Калеб” яшьләр буыны җыены, Бөтендөнья татар яшьләре форумы,Татарстан Республикасы Язучылар берлеге һәм “Ялкын” журналы тарафыннан оештырылган «Үз юлым» иҗади конкурс-лабораториясенең өченче этабы узды. Бу файдалы, эчтәлекле чара Язучылар берлегендә үтте. Иртәнге унда ачылу тантанасы башланды. Анда безне язучы-остазларыбыз Нәбирә Гыйматдинова, Ркаил Зәйдулла һәм Халисә Ширмән белән якыннанрак таныштырдылар. Вакытның һәр минуты эшлекле булганга, сизелмәде дә үтте.

Без, төрле районнардан, төрле шәһәрләрдән килгән конкурсантлар, алдан ук билгеләнгән язучылар белән төрле бүлмәләргә таралышып эшләдек.

Мин Нәбирә Гыйматдинова төркеменә эләгүемне белгәч, бик сөендем, чөнки алдан ук аның оста язучы икәнен белә идем. Ул исә үзе, барлык әсәрләрне укып, безгә хаталарыбызны төзәтергә булышты, киңәшләрен бирде.

Сәгать уникедә без кофе-брейкка туктадык. Сәгать көндезге бердә остаханәләр эшен дәвам итте. Башлап язучылар өчен, Химиклар мәдәният сараенда “Серләүхәсез” вербатимы үтте. Ул үз теленнән оялган татарлар турында иде.

Без иҗат букчабыз тулы бүләкләр белән өйләребезгә таралаштык, тик озакка түгел. Апрель ае дәвамында без онлайн режимда интернет аша аралашып торачакбыз. Ә инде ай ахырында җиңүчеләр билгеле булачак.

Минемчә, әлеге көн минем исемнән мәңге чыкмас, чөнки мондый танылган язучылар белән күрешеп, сөйләшү – ул үзе зур бәхет!

*Р. Шәрипов*

## *Республиканские курсы повышения квалификации учителей начальных классов*



21 апреля на базе нашей школы прошла Республиканская стажировка учителей начальных классов по теме «Разработка урока в начальной школе по технологии активных методов обучения в условиях реализации ФГОС НОО». В этот день Лилия Рахимзянова, Ляйсан Алмаева, Фарида Гафарова, Айгуль Сабирзянова провели открытые уроки. А Клара Галиуллина, Венера Мухутдинова и Алина Мухаметгалиева показали внеклассное мероприятие в форме интеллектуальной игры «Клуб знатоков» .

## *Тырышлыкның нәтиҗәсе булса күңелле...*

Тукай көннәре якынлашканда,мәктәбебез туган тел, әдәбият сөючеләрнең киң мәйданын хәтерләтә шикелле. Күптөрле чаралар, кичәләр ,конкурслар ,иҗади бәйгеләр киң колач ала. Бәйрәм көннәрендә генә түгел,башка вакытта да туган телебезне хөрмәтлибез һәм аңа карата һәрчак игътибарлы без .. Нәтиҗәләребез дә куанычлы: 2016 -17 нче уку уку елында татар теленнән Республикакүләм уздырылган олимпиадада 6 А сыйныфы укучысы Никитина Эльзана призер (укытучысы Нәбиуллина Ф.Х.), 9 А сыйныфы укучысы Хадыкина Екатерина Җиңүче булды (укытучысы Мөбәрәкшина Г.Р.) Хадыкина Екатерина 18-21 нче апрель көннәрендә Казанда булып узган татар теле буенча V Халыкара олимпиадада катнашашты, уңышлы чыгыш ясады. ТР Мәгариф һәм Фән Министрлыгының Дипломы белән бүләкләнде. Туган телебезгә карата игътибар бервакытта да кимемәсен иде.Киләчәк буыннарны да үз ана телебедә тәрбияләргә насыйп булсын!

## *Горур аккош*

Бер-берсенең җан җылысын тоеп
Матур гына йөзә аккошлар
Тыйнаклыгы, нәфислеге белән
Кешеләргә үрнәк бу кошлар.

Күл пычранса , яшәү түмен җуяр
Көч табармы канат кагарга?
Горурлыгы белән исәпләшми
Мәҗбүр була чүпне җыярга.

Кошлар булып,кошлар аңлый сыман
Табигатьнең матур бер ямен.
Тик, кешеләр, нигә гамьсез соң сез?!
Белмибез җир- ана кадерен.

*М. Хазиева*

## *Школа Превосходства*

22 апреля на базе нашей школы прошел семинар заместителей директоров и учителей Школ Превосходства в рамках Республиканского проекта «Инновационный потенциал Школ Превосходства Республики Татарстан». Наталья Абызова, Фардия Набиуллина, Гульнара Сафина, МиляушаХайруллина, Эльмира Забирова,

## *Школьная жизнь…*

**Международный день птиц**

1 апреля повсюду отмечается Международный день птиц. В честь этой знаменательной даты 31 марта в актовом зале школы учитель биологии Файзрахманова Г.А. с обучающимися 10Б класса подготовила и провела познавательное мероприятие “Удивительные птицы"“.

**Наука и мы**



4 апреля в Арском педагогическом колледже им. Г.Тукая прошла X муниципальная научно-практическая конференция студентов и школьников " Наука и мы", посвященная Году экологии в России. Обучающийся 10б класса Набиуллин И. (учитель Набиуллина Ф.Х.) занял I место, обучающаяся 10б класса Шамсутдинова А. (учитель Нурмихаметова И.И.) - I место, обучающаяся 10б класса (учитель Валиуллина Р.Г.) - II место, обучающаяся 8в класса Байгубикова Г. (учитель Фатыхова Л.А.) награждена дипломом в номинации "За перспективную исследовательскую работу". Поздравляем учеников и их учителей!

**Спортивная жизнь**

7 апреля в спортивном зале школы прошли “Веселые старты" среди обучающихся 5-х классов, которые провел Набиуллин Р.Р. Почетное 1 место заняла команда 5а класса. Поздравляем их!



**Созвездие-Йолдызлык-2017**

10 апреля обучающаяся 4б класса Р. Гапдерахманова с руководителем Мухаметгалиевой А.Ф. приняли участие в суперфинале XVII Открытого республиканского телевизионного молодежного фестиваля эстрадного искусства «Созвездие-Йолдызлык-2017» во второй младшей группе номинации “Вокал-соло”.

**День космонавтики**

13 апреля в актовом зале школы прошло замечательное мероприятие для обучающихся 9-10 классов под названием «Мы и космос». Провела мероприятие учитель физики Сабирова М.Л. В фойе школы была организована выставка рисунков.



**V Международная олимпиада по татарскому языку**

Обучающаяся 9а класса Хадыкина Екатерина (руководитель - Г.Р.Мубаракшина), отлично выступив на V Международной олимпиаде по татарскому языку, удостоилась Диплома и ценных подарков. Поздравляем и желаем дальнейших побед!



**День защиты детей**

29 апреля в нашей школе прошло мероприятие, посвященное Дню защиты детей по гражданской обороне. Оно проходило в нескольких этапах: разжигание костра, кочки, изготовление ватно-марлевой повязки, первая медицинская помощь, переноска пострадавшего и стрельба из пневматической винтовки. Цель проведения мероприятия: научить детей вести себя в экстримальных ситуациях.

**Без бергә**

29 апреля в Кукморе прошел зональный этап Республиканского Фестиваля-конкурса детского народного творчества «Без бергә» . В нем приняли участие одержали победу учащиеся нашей школы Н. Зарина - II место, дуэт РозалИс - III место. А. Нияз был награжден дипломом участника.

**Двухмесячник «Чистый город»**

Весь апрель и май в нашей школе проходит двухмесячник под названием «Чистый город». Все обучающиеся школы продолжают принимать участие в субботниках.

**Неделя татарского языка**

В рамках недели татарского языка в школе прошли познавательные мероприятия, посвященные 131 летию со дня рождения великого татарского поэта Г. Тукая. Все учителя дали открытые уроки, посетили музеи и Арскую центральную библиотеку.

**Редакторы газеты:**

Р.Б.Хабреева-учитель русского языка